**Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты**

**Карар**

**2023 нче елның 27 нче февраленән** **№20**

«Өркеш авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үләннәр, яфракларны һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү һәм янгын сүндерү максатларында су алу өчен шартлар тудыру турында» 2017 елның 26 декабренең Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетының 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Өркеш авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү һәм янгын сүндерү максатларында су алу өчен шартлар тудыру турында» 2017 елның 26 декабренең Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетының 6 нчы номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карар преамбуласында «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 947 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак пунктларның гомуми файдалану җирләрендә, шулай ук торак пунктларның территорияләрендә урнашкан шәхси йортлар территорияләрендә, махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ризык әзерләү өчен ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яки эшләнмәләр яндыру тыела.».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе: А.Ш.Әгъләмова